Быел экология елы һәм табигатьне тагы да сакларга һәм якларга тиешбез. Белгәнебезчә, «Керпеләр яшәргә тиеш! » Ботенроссия экологик акциясе бара. Анын кысаларынна Мордовия мәктәпләрендә «Батарея тапшыр – керпене саклап кал» дигән акция игълан ителде һәм кондәлек тормышта (сәгатьләрдә, пультларда) кулланылган батареяларны жыюга старт бирелде. Нигә батарея, дисезме. Чонки чvплеккә ташланган бер батарея туфракка эләккәннән сон 20 квадрат метр жирне зарарлый. Географлар урманнар зонасында шул территориядә ике сукыр тычкан, бер керпе, берничә мен янгыр суалчаны яши алыр иде дип саныйлар. «Призыв» дигән район газетасында Ләмберә беренче номерлы мәктәбе балаларынын «Керпеләр яшәргә тиеш!» экология акциясендә, ин активларнын берсе буларак, кулланыштан чыккан батарейкалар жыюлары турында язган иделәр. Бу мәктәп укучылары барлыгы 1445 батарейка жыеп алганнар, икән. Шулай иттереп, укучылар бик кvп керпе саклаганнар булып чыга. Нинди зур файда! Мәсәлән, бер батарейка авыр металлар - цинк, ртуть, кремний... белән бер керпе яшәрлек жирлекне пычрата, димәк 1445 керпене коткарганнар дип санарга була.
Бу эштә ин активларны әйтмәсәк, дорес булмас кебек тоела. Алар: 1 «А» сыйныф укучылары, житәкчеләре Р.Ш. Хусаинова белән Шәмил Бикулов, Аделина Сяфукова һәм Эмир Исякаев. 3 «Б»да Аделина Сявкаева һәм Карина Аитова (житәкчеләре Э.Х Искандярова). 4 «Б» сыйныфында Александр Беляев, Давид Маргарян һәм Даша Митин, житәкчеләре Е.В. Никишанина белән батарейка жыюда бик тә актив булдылар. Ә 1 «Б» классында ин кvп батарейканы Иван Рубцов (житәкчесе Г.А. Яфуняева) жыйган, 2 «А»да - Анна Шамаева (житәкчесе В.М. Архипова), 3 «А»да - Булат Одинцов һәм Сабир Аймуранов (житәкчеләре К.И. Карникова), 4 «А»да - Александр Станченков (житәкчесе Е.В. Пугачева), 5 «Б»да - Лилия Солдатова (житәкчесе К.Р. Ишкиняева) һәм 7 «Б»да - Динара Биктеева белән Карина Файсханова (житәкчеләре А.В. Базакина) батарейкаларны жыеп, керпеләрне виртуаль vлемнән коткарганнар.
Табигать – ул чиксез хәзинә. Планетабызны, анын табигатен саклау – бvген кешелекнен ин моһим бурычларыннан берсе. Һәр кеше vзе яшәгән жирне, анын табигатен яратырга, байлыкларын сакларга, киләчәгебез турында уйланып яшәргә тиеш. «Керпеләр яшәргә тиеш!» Ботенроссия экологик акциясе ноябрь ахырына кадәр дәвам итәчәк. Анда һәркем катнаша ала.